СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2022 елның 10 ноябре № 22/4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турындагы мәгълүматка үтемлелекне тәэмин итү турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль законга, «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 312-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2019 елның 28 гыйнварындагы 33/2 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**5 бүлекнең 4 пунктчасын** киләсе яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм аңа буйсынучы оешмаларның, күрсәтелгән органнарның һәм оешмаларның дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану хокукын һәм аны гамәлгә ашыруның билгеләнгән тәртибен боза торган вазыйфаи затларының актларына һәм (яисә) гамәлләренә (гамәл кылмавына) билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә;»;

**9 бүлекнең 2 пунктында** «Интернет челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2007 елның 14 мартындагы 14/8 номерлы карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районының дәүләт милкендәге һәм муниципаль милкендәге җир

кишәрлекләрен бирү тәртибенең **8.2 пунктына** түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**6 абзацны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта күрсәтелгән гаризаны һәм кирәкле документларны алган датадан ике атна эчендә Палата «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2_7 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген тапшыруны алдан килештерү турында карар кабул итәргә, яки милеккә тапшыру, яки арендага бирү турында карар кабул итәргә, яисә аны тапшыруны алдан килештерүдән баш тарту, яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итәргә тиеш.»;

**7 абзацны төшереп** калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 8.2.1 пунктын өстәргә:

«8.2.1. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турындагы карар «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы нигезләмәләре белән билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, Россия Федерациясе Җир кодексының 39_17 статьясында каралган тәртиптә җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү өчен нигез булып тора.».

3. Әлеге карар, әлеге карарның 1 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның 1 пункты 2022 елның 1 декабреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы урынбасары, Татарстан
Республикасы Чүпрәле муниципаль районы
Советы Рәисе урынбасары: А.Е. Ярухин